Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлегенең Көлкәш авылында 2019 елның 8 ноябрендә кабул ителгән 1/1 нче номерлы "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлегенең Көлкәш авылында 2020 елда үзара салым кертү турында ” халык җыены карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Сез

- Көлкәш авылында су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау (шул исәптән, су линияләрен салу һәм ремонтлау, суэтем башняларын ремонтлау, чыгым материаллары сатып алу) ;
- Көлкәш авылы мәчете янындагы чишмә тирәсен чистарту һәм төзекләндерү, мәчет тирәсен төзекләндерү;
- Көлкәш авылында беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү максатларында гидрантлар һәм башка материаллар, шулай ук эшләр һәм хезмәтләр сатып алу ;
- Көлкәш авылында калдыкларны вакытлыча җыю урыннарын чистарту һәм рекультивацияләү эшләрен башкарып җирле мәсьәләләрне чишү максатында тоту өчен шушы җирлектә яшәүче балигъ булган, Көлкәш авылы территориясендә теркәлгән һәр кеше исәбеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентларны, бала вакытыннан инвалидларны, колясkalы инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, күп балалы гаиләләрне кертмичә) 2020 елда 2000 (Ике мең) сум күләмендәге үзара салым кертү белән килешәсезме? «ӘЙЕ» «ЮК» соравы буенча 08.11.2019 үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыены беркетмәсе нигезендә

халык җыены карар итте:

1.

- Көлкәш авылында су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау (шул исәптән, су линияләрен салу һәм ремонтлау, суэтем башняларын ремонтлау, чыгым материаллары сатып алу) ;
- Көлкәш авылы мәчете янындагы чишмә тирәсен чистарту һәм төзекләндерү, мәчет тирәсен төзекләндерү;
- Көлкәш авылында беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү максатларында гидрантлар һәм башка материаллар, шулай ук эшләр һәм хезмәтләр сатып алу ;

Көлкәш авылында калдыкларны вакытлыча җыю урыннарын чистарту һәм рекультивацияләү эшләрен башкарып җирле мәсьәләләрне чишү максатында тоту өчен шушы җирлектә яшәүче балигъ булган, Көлкәш авылы территориясендә теркәлгән һәр кеше исәбеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентларны, бала вакытыннан инвалидларны, колясkalы инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, күп балалы гаиләләрне кертмичә) 2020 елда 2000(Ике мең) сум күләмендәге үзара салым кертергә.

2.Халык җыены нәтиҗәләрен информацион стендларда һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында игълан итәргә.

Кызылтау авыл җирлеге Башлыгы Ш. Р. Гаффаров